Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XXXVI - 2**

Балык Бистәсе штп. 2014 елның 28 марты

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы Регламентын раслау турында

Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының җирле үзидарә турындагы законнарына үзгәрешләр кертелүгә, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары карарларына коррупция күренеше өчен шартлар тудыруга ярдәм итүче нигезләмәләрне кертүне кисәтүгә, шулай ук «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 22 маддәсендәге 8 өлешенең 11 пункты нигезендә үз эшчәнлеген оештыру һәм процедура мәсьәләләрен җайга салу максатларында мондый нигезләмәләрне ачыклау һәм бетерүгә юнәлдерелгән закон актларын кабул итүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Кушымтага ярашлы рәвештә Балык Бистәсе муниципаль район Советы Регламентын расларга.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы Регламенты турында» 2005 елның 7 декабрендәге III-3 номерлы карарын, «Балык Бистәсе муниципаль район Советы Регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» 2009 елның 1 декабрендәге XXXXIII-2 номерлы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырып халыкка игълан итәргә.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г. Вәлиев

Кушымта.
Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2014 елның 28 мартындагы XXXV-2 номерлы карары белән расланды

**Татарстан Республикасы**
**Балык Бистәсе муниципаль район Советы**
**Регламенты**

## 1 Бүлек. Гомуми нигезләмәләр

### 1 маддә

1. Әлеге Регламент Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы эшчәнлеген оештыру мәсьәләләрен җайга сала (алга таба – район Советы), район Советы утырышларын чакыру, әзерләү һәм уздыру тәртибен, аның утырышларында карала торган мәсьәләләр буенча фикер алышу һәм карарлар кабул итү, даими комиссияләрне, депутат төркемнәрен, районның башка органнарын төзү тәртибен һәм аларның вәкаләтләрен билгели, район Советы һәм аның депутатларының үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибенә бәйле башка мәсьәләләрне көйли.

2. Әлеге Регламентны үтәү район Советы депутатлары, муниципаль районның җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары, район Советы утырышларында катнашучы, депутатларның мөрәҗәгатьләрен һәм сорауларын караучы башка затлар өчен мәҗбүри булып тора.

### 2 маддә

1. Район Советы эшчәнлеге коллектив һәм ирекле фикер алышу һәм мәсьәләләрне хәл итү принципларына нигезләнә.

### 3 маддә

1.Район Советы эшенең төп формасы – аның район Советы компетенциясенә кертелгән мәсьәләләрне хәл итә торган сессияләре.

2.Район Советы сессияләре ачык һәм хәбәрдарлыкта үткәрелә.

3. Район Советы ябык утырышны уздыру турында карар кабул итәргә мөмкин.

### 4 маддә

1. Район Советы, аның даими комиссияләре, район Советы депутатлары, район Башлыгы - район Советы рәисе һәм аның урынбасарының эшчәнлеген хокукый, оештыру, документаль, мәгълүмати, матди - техник яктан тәэмин итү Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппараты турындагы Нигезләмә нигезендә район Советы Аппараты гамәлгә ашыра.

## 2 Бүлек. Район Советы депутаты

**5 маддә**

1. Район Советы депутаты вәкаләтләре аны җирлек Башлыгы яисә җирлекнең вәкиллекле органы депутатлары арасыннан район Советы депутаты итеп сайлаган көннән башлана һәм яңа чакырылыш район Советы эшли башлаган көннән туктатыла.

2. Депутат үз эшчәнлеген район Советы тарафыннан расланган депутат статусы турындагы Нигезләмә һәм әлеге Регламент нигезендә башкара.

**6 маддә**

1. Уртак эшчәнлек һәм район Советы тарафыннан карала торган мәсьәләләр буенча бердәм позиция белдерү өчен Совет депутатлары партия, территориаль, һөнәри яки башка принцип буенча әлеге Регламентта билгеләнгән тәртиптә даими яки вакытлыча депутат берләшмәләренә – фракцияләргә яки төркемнәргә берләшергә хокуклы (алга таба – депутат берләшмәләре). Район Советы депутаты бары тик бер депутат берләшмәсендә генә торырга хокуклы.

2.Депутатлар берләшмәсе составында район Советының кимендә 5 депутаты булырга мөмкин.

3. Фракцияләр һәм депутат төркемнәре тигез хокукларга ия.

4. Аларны теркәгәндә депутат берләшмәләренең берсенә дә кермәгән яисә депутат берләшмәсеннән киткән район Советы депутатлары алга таба депутат берләшмәсе ризалыгы белән аларның һәркайсына керергә мөмкин.

4. Депутат берләшмәләренең эчке эшчәнлеге алар тарафыннан мөстәкыйль рәвештә оештырыла.

6. Депутат берләшмәләре район Башлыгына - район Советы рәисенә кабул ителгәннән соң өч көн эчендә үзләренең карарлары турында хәбәр итәләр.

**7 маддә**

1. Депутат берләшмәсен теркәү өчен район Башлыгына - район Советы рәисенә түбәндәге документларны җибәрәләр:

а) депутат берләшмәсен төзү турында депутат берләшмәсе җитәкчесенә язмача хәбәрнамә;

б) депутат берләшмәсенең аны төзү максатлары турында карарны үз эченә алган оештыру җыелышы беркетмәсе, аның рәсми исеме, исемлек составы, шулай ук депутат берләшмәсе исеменнән чыгыш ясарга һәм аны район Советы һәм аның органнары утырышларында тәкъдим итәргә вәкаләтле затлар турында;

в) депутат берләшмәсенә керүе турында район Советы депутатларының язма гаризалары.

2. Барлык теркәлгән депутат берләшмәләре район Советы депутат берләшмәләре реестрына кертелергә тиеш.

3. Депутат берләшмәсен төзү максатларында аның вәкиленә тиешле депутат берләшмәсе таләбе буенча сүз бирелә.

4. Әлеге статья нигезендә теркәлмәгән депутат берләшмәләре әлеге Регламентта билгеләнгән депутат берләшмәсе хокукларыннан файдаланмыйлар.

**8 маддә**

1. Депутат берләшмәләре хаклы:

а) район Башлыгын - район Советы рәисен һәм район башлыгы урынбасарын - район Советы рәисе урынбасарын сайлау өчен кандидатуралар турында алдан фикер алышу;

б) район Советында карала торган мәсьәләләр буенча фикер алышу үткәрә;

в) башка фракцияләр, депутат төркемнәре белән консультацияләр һәм башка килештерү чаралары уздыра;

г) район Советы депутатлары арасында үз программаларын, тәкъдимнәрен, мөрәҗәгатьләрен һәм башка материалларны таратырга;

д) теләсә нинди мәсьәлә буенча район Советы утырышында чыгыш ясарга;

е) үз вәкилләрен вакытлыча депутат комиссияләренә, эш төркемнәренә, шул исәптән килештерү комиссияләренә кертергә;

ж) үз фракциясе, депутат төркеме арасыннан район Советында теләсә кайсы постка сайлау өчен кандидатуралар тәкъдим итәргә;

з) законнар белән тыелмаган башка эшчәнлекне гамәлгә ашыру.

2. Төрле фракцияләр һәм депутат төркемнәре вәкилләренең уртак карарларын эшләү өчен уртак консультацияләр, киңәшмәләр, утырышлар үткәрелергә мөмкин.

**9 маддә**

. 1.Депутат берләшмәләрен ел саен яңадан теркәп барырга. Депутат берләшмәсен яңадан берләштерү өчен депутат берләшмәләре җитәкчеләре район Башлыгы - район Советы рәисе исеменә депутат берләшмәсенең саны һәм составы турында белешмәләр җибәрә.

2.Әгәр әлеге Регламент нигезендә теркәлгән депутат берләшмәсе әгъзаларының саны район Советының 5 депутатыннан кимрәк булса, мондый депутат берләшмәсе район Советының депутат берләшмәләре реестрыннан төшереп калдырылырга тиеш, бу хакта район Башлыгы - район Советының якындагы утырышында район Советы рәисе депутатларга хәбәр итә.

## 3 Бүлек. Район Башлыгын, район башлыгы урынбасарын сайлау.

**10 маддә**

. 1.Район Башлыгы яңа сайланган муниципаль район Советының беренче сессиясендә район Советы депутатлары арасыннан яшерен тавыш бирү юлы белән сайлана. Район Башлыгы район Советы рәисе вәкаләтләрен башкара.

2. Район Башлыгын сайлау район Советы депутатлары тәкъдим иткән кандидатлар арасыннан, шул исәптән район халкы, иҗтимагый берләшмәләр, Татарстан Республикасы Президенты тәкъдимнәре нигезендә гамәлгә ашырыла.

3. Район Башлыгы вазыйфасына сайлану өчен тәкъдим ителгән депутат үзенең кандидатурасын кире алу турында белдерергә хокуклы.

**11 маддә**

Район башлыгы вазыйфасына сайлану өчен тәкъдим ителгән кандидатуралар буенча, кандидатурасын алу турында белдерүчеләрдән тыш, фикер алышу үткәрелә. Фикер алышу барышында кандидатлар булачак эшчәнлек программасы белән чыгыш ясыйлар һәм депутатларның сорауларына җавап бирәләр.

Һәр депутат үзләренә тәкъдим ителгән программа турында үз фикерен әйтергә, кандидатураны яклап яисә аңа каршы агитацияләргә хокуклы.

1. Район Башлыгы вазыйфасына сайлануга тәкъдим ителгән кандидатуралар турында фикер алышканнан соң, үзләрен кире алуны белдерүчеләрдән тыш, барлык кандидатлар да яшерен тавыш бирү өчен бюллетеньгә кертелә. Һәр депутат бер генә кандидат өчен тавыш бирә ала.

2. Кандидат район Башлыгы вазыйфасына сайланган дип санала, әгәр аны сайлау өчен район Советы депутатларының билгеләнгән саныннан яртысыннан артыгы тавыш биргән булса.

3. Әгәр район Башлыгы вазыйфасына кандидатларның берсе дә депутатларның тавышын сайлау өчен таләп ителгән тавышларны җыймаса, кандидатларны кабат күрсәтү уздырыла. Шул ук вакытта элегрәк чыккан кандидатларны күрсәтү рөхсәт ителә.

4. Әгәр район башлыгы вазыйфасына икедән артык кандидат тәкъдим ителгән булса, шуларның берсе дә депутатлар тавышын сайлау өчен таләп ителгән депутатларны җыймаган булса, район Советы карары нигезендә, утырышта катнашучы депутатлар саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителгән карар нигезендә, иң күп тавыш җыйган ике кандидатура буенча тавыш бирүнең икенче туры уздырыла. Әгәр икенче турда район башлыгы сайланмаган булса, район башлыгы вазыйфасына кандидатлар күрсәтү процедурасы кабатлана.

**12 маддә**

1. Район Башлыгы сайланганнан соң түбәндәге ант бирә:

«Муниципаль берәмлек Башлыгы вазыйфасына керешкәндә, ант итәм: миңа муниципаль берәмлек Уставы тарафыннан бирелгән үз вәкаләтләремне башкарганда, хәзерге һәм киләчәк буыннар алдында муниципаль берәмлек өчен җаваплылыкны аңлап, Россия Федерациясе Конституциясен, федераль законнарны, Татарстан Республикасы Конституциясен һәм Татарстан Республикасы законнарын, муниципаль берәмлек уставын төгәл үтәргә, муниципаль берәмлек халкының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен хөрмәт итәргә, сакларга һәм якларга, тарихи традицияләрне граждан татулыгына һәм икътисадый потенциалны арттыруга омтылырга, муниципаль берәмлекнең чәчәк атуы өчен һәм аның барлык халкы хакына гадел, намус белән бурычларымны үтәргә».

**13 маддә**

1. Район Башлыгы:

1) районны башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, дәүләт хакимияте органнары, гражданнар һәм оешмалар белән мөнәсәбәтләрдә тәкъдим итә, ышанычнамәсез район исеменнән эш итә;

2) район Советы эшен оештыра, район Советы сессиясен чакыра һәм аларда рәислек итә;

3) әлеге Устав билгеләгән тәртиптә район Советы кабул иткән норматив хокукый актларга кул куя һәм халыкка җиткерә;

4) үз вәкаләтләре чикләрендә район Советы эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча хокукый актлар чыгара;

5) район Башкарма комитеты җитәкчесе белән контракт төзи;

6) район Советы эшендә җәмәгатьчелек фикеренең хәбәрдарлыгын һәм аны исәпкә алуны тәэмин итү чараларын күрә;

7) гражданнарны кабул итүне, аларның мөрәҗәгатьләрен, гаризаларын һәм шикаятьләрен карауны оештыра;

8) район Советы сессияләре беркетмәләренә имза сала;

9) район Советы Аппараты эше белән җитәкчелек итә;

10) район Советының контроль вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны җайга сала;

11) район Советын карап тоту һәм аның эшчәнлеген тәэмин итү өчен район бюджетында каралган чыгымнар буенча эш итүче булып тора;

12) закон һәм әлеге Устав нигезендә гражданнарның турыдан-туры ихтыярын белдерү юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру буенча район Советының хокукый актын кабул итүне оештыра;

13) район җирле үзидарә органнарының федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, башка федераль органнар, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, район территориясендә гамәлдә булган органнары белән кирәкле хезмәттәшлеген тәэмин итә;

14) район исеменнән икътисадый һәм социаль-мәдәни өлкәләрдә хезмәттәшлек турында дәүләт хакимияте органнары, башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары белән шартнамәләр һәм килешүләр, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән үзара хезмәттәшлек итү һәм гамәлләрне координацияләү турында килешүләр төзи;

15) җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне һәм җирле үзидарә органнарына федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен хәл итү буенча җирле үзидарә органнары тарафыннан вәкаләтләр гамәлгә ашыруны тәэмин итә;

16) федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары белән муниципаль районнар башлыклары карамагына кертелгән башка вәкаләтләрне, шулай ук район Уставы, район Советы карарлары белән район Башлыгы компетенциясенә кертелгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

**14 маддә**

1. Район Башлыгы тәкъдиме белән район Советы депутатлары арасыннан район Башлыгы урынбасарлары сайлана.

Район башлыгы урынбасарлары яшерен яки ачык тавыш бирү юлы белән сайланалар. Тавыш бирү ысулын сайлау турындагы карар район Советы карары белән билгеләнә.

2. Район Советы депутаты, район Советы депутатларының билгеләнгән саныннан яртысыннан күбрәге сайласа, район Башлыгының сайланган урынбасары булып санала.

3. Район Башлыгы урынбасарлары район Башлыгы боерыгы белән билгеләнгән вазыйфаларны бүлү нигезендә аның йөкләмәләрен үтиләр. Район Башлыгы вакытлыча (авыру яки отпуск белән бәйле) булмаган яисә үз вазыйфаларын

вакытында үтәмәгән очракта, үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы район Башлыгы урынбасары район Башлыгы - район Советы рәисе вазыйфаларын башкара.

4. Район Башлыгы азат ителгән нигездә ике урынбасарны һәм азат ителмәгән нигездә ике урынбасарны сайларга тәкъдим итәргә хокуклы.

5. Район Башлыгы урынбасарларының вәкаләтләре район Уставында каралган нигезләрдә вакытыннан алда туктатыла.

6. Район Башлыгы урынбасарлары статусына бәйле башка чикләүләр федераль кануннарда билгеләнгән.

7. Район Башлыгы урынбасарлары район Башлыгы инициативасы буенча кабул ителә торган район Советы карары нигезендә яисә депутатлар төркеме таләбе буенча район Советы депутатларының билгеләнгән санынннан кимендә өчтән бере күләмендә вазыйфадан теләсә кайсы вакытта алынырга мөмкин. Район Башлыгы урынбасарларын чакыртып алу турындагы карар район Советы депутатларының билгеләнгән саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

## 4 Бүлек. Район Советының даими комиссияләре

### 15 маддә

1. Район Советы компетенциясенә кертелгән мәсьәләләрне алдан карау һәм әзерләү өчен депутатлар арасыннан, район Башлыгыннан һәм аның урынбасарларыннан гайре, район Советы эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча даими комиссияләр төзелә, шулай ук вакытлы комиссияләр төзелергә мөмкин.

2.Муниципаль программаларны, район Советы карарлары проектларын әзерләү, район карамагына кертелгән аеруча мөһим мәсьәләләр буенча фикер алышу өчен район Советы каршында депутатлар, район башкарма комитеты, иҗтимагый берләшмәләр, оешмалар һәм предприятиеләр, белгечләр, экспертлар һәм район халкы составында эшче, эксперт һәм башка киңәшмә төркемнәре төзелергә мөмкин.

### 16 маддә

1. Район Советының үз компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча даими комиссияләре:

1) район Советы карары проекты буенча бәяләмәләр әзерлиләр;

2) районны, район бюджетын үстерү планнары һәм программалары проектларын тикшерүдә катнашалар, алар буенча үзенең искәртүләрен һәм тәкъдимнәрен кертәләр;

3) район Советы, район Башлыгы - район Советы рәисе кушуы буенча яки комиссия эшчәнлеге өлкәсенә караган сораштырулар буенча әзерлиләр, алар буенча район Советының хокукый актлары проектларын әзерлиләр;

4) үз компетенциясе чикләрендә район Советының хокукый актларын үтәүне тикшереп торалар, шушы сораштырулар буенча тиешле органнарның һәм җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларының докладларын һәм хисапларын тыңлыйлар;

5) район Советы утырышында карау өчен документлар проектларын әзерлиләр;

6) район Советына яисә район Башлыгына җирле әһәмияттәге аеруча мөһим мәсьәләләрне халык тикшерүенә чыгару яисә гавами тыңлаулар билгеләү турында тәкъдимнәр белән мөрәҗәгать итәләр;

7) әлеге Регламентта каралган тәртиптә район Советының чираттан тыш сессиясен чакыру турында тәкъдимнәр кертәләр;

8) район Уставында һәм әлеге Регламентта каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыралар.

**17 маддә**

1. Район Советының даими комиссияләре район Советы депутатлары тарафыннан комиссия рәисе һәм әгъзалары составында район Советы депутатларының билгеләнгән санынннан күпчелек тавыш белән сайланалар.
2. Район Советының даими комиссияләренең санлы составы 7 депутаттан ким була алмый, ул яңа төзелгән район Советының беренче сессиясендә билгеләнә.
3. Район Советының даими комиссияләрен сайлаганда тавыш бирү тулаем составта уздырыла.
4. Район Советының даими комиссияләре рәисләре альтернатив нигездә сайланалар. Комиссия рәисе вазыйфасына кандидатуралар аның утырышында алдан каралырга тиеш.
5. Район башлыгы - район Советы рәисе тәкъдиме буенча район Советының даими комиссияләре комиссия рәисе урынбасарын сайлыйлар.
6. Район Советы депутаты район Советының ике комиссиясе әгъзасы булырга мөмкин.

**18 маддә**

1. Район Советының даими комиссияләре рәисләре:

1) комиссияләр эшчәнлеген оештыралар;

2) комиссия утырышының көн тәртибен һәм чакырылган затлар исемлеген төзиләр;

3) комиссияләр утырышларын алып баралар;

район Советының башка комиссияләре, район Башлыгы - район Советы рәисе, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар, массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара мөнәсәбәтләрдә комиссияне тәкъдим итә;

4) комиссия карарларына имза сала;

5) әлеге Регламентта каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыралар.

**19 маддә**

1. Комиссия составының кимендә өчтән икесе катнашса, район Советының даими комиссияләре утырышлары тулы хокуклы.
2. Район Советының даими комиссиясе карарлары комиссияләр әгъзаларының билгеләнгән санынннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.
3. Район Советының берничә даими комиссиясенең уртак утырышларын уздырганда, карарлар һәр комиссия әгъзаларының билгеләнгән санынннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

**20 маддә**

1. Район Советының даими комиссияләре үз эшләренә җирле үзидарә органнары вәкилләрен, шул исәптән район Башкарма комитетының, дәүләт органнарының, җәмәгать оешмаларының структур бүлекчәләрен, экспертларны, белгечләрне җәлеп итәргә хокуклы.

**21 маддә**

1. Район Советының даими комиссияләре утырышларында район Советының киңәш бирү тавышы хокукына ия депутатлары катнаша ала.

**22 маддә**

1. Район Советы кирәк булганда вакытлы комиссияләр дә төзи ала.
2. Күрсәтелгән комиссияләрнең бурычлары, вәкаләтләре һәм эшчәнлек сроклары алар төзелгәндә район Советы тарафыннан билгеләнә. Вакытлы комиссияләр район Советы депутатларының билгеләнгән санынннан күпчелек тавыш белән комиссия рәисе һәм әгъзалары составында депутатлар арасыннан төзелә.

**23 маддә**

1.Вакытлы комиссияләр үзләренең эш нәтиҗәләре буенча район советына мәсьәләнең асылы буенча доклад тапшыралар, шуңа бәйле рәвештә ул булдырылган иде. Үзенчәлекле фикере булган комиссия әгъзалары аны район Советы утырышында игълан итәргә хокуклы. Вакытлы комиссияләр доклады буенча район Советы карар кабул итәргә мөмкин.

2. Вакытлы комиссияләр үз эшчәнлекләрен аңа йөкләнгән бурычларны үтәгәннән соң яисә район Советы карары белән вакытыннан алда туктаталар.

**5 Бүлек. Район Советының эш тәртибе**

**24 маддә**

1. Яңа чакырылыш район Советы беренче сессиягә район Советы депутатларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән икесе сайланган көннән алып 30 көн эчендә җыела. Сайлаулардан соң беренче сессияне район Советының элеккеге чакырылышы белән сайланган район Башлыгы, ә ул булмаганда район Башкарма комитеты җитәкчесе чакыра һәм әзерли.

2. Район Советы сессиясен район Башлыгы сайланганчы яше буенча иң өлкән район Советы депутаты ача һәм алып бара.

**25 маддә**

1. Район Советының чираттагы утырышлары кирәк булганда уздырыла, әмма ким дигәндә өч айга бер тапкыр. Җәйге вакытта сессияләр арасындагы тәнәфесләр озынрак булырга мөмкин. Чираттан тыш сессияләр район Башлыгы яки депутатлар төркеме тәкъдиме белән район Советы депутатларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән бере тәкъдиме белән чакырыла. Район Советы сессиясе, анда район Советының сайланган депутатлары санының 50 проценттан да ким булмаган өлеше катнашса, хокуклы.

2. Район Советы сессиясенә район Советына сайланган депутатларның 50 проценттан да кимрәк өлеше килсә, район Башлыгы карары белән сессия башка вакытка күчерелә, әмма җиде көннән дә артыкка түгел.

3. Район Советы депутатларына һәм чакырылган затларга чираттагы утырышны үткәрү вакыты, урыны, район Советы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында биш көннән дә соңга калмыйча, ә чираттан тыш утырыш уздырылганчы бер көннән дә соңга калмыйча хәбәр итәләр. Район Советы утырышын

уздыру урыны һәм вакыты турындагы хәбәр массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыгарга мөмкин.

**26 маддә**

1. Район Советы утырышлары район хакимияте бинасының актлар залында түбәндәге адрес буенча уздырыла: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Балык Бистәсе штп., Ленин ур., 48, анда Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы һәм Балык Бистәсе муниципаль районы флагы һәм гербы урнаштырылган була.
2. Утырышлар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Дәүләт гимнын башкару белән ачыла һәм ябыла.
3. Район Советының утырышлар залында район Башкарма комитеты, гаммәви мәгълүмат чаралары вәкилләре өчен махсус урыннар билгеләнә.

**27 маддә**

1. Район Советы утырышына килгән депутатларны теркәү район Советы утырышы ачылуга бер сәгать кала башлана.
2. Депутатларны теркәүне район Советы Аппараты оештыра, ә район Советы утырышын ачканнан соң - секретариат.

**28 маддә**

1. Район Советы сессиясен район Башлыгы – район Советы рәисе, ул булмаган очракта район Башлыгы урынбасары - район Советы Рәисе урынбасары алып бара. Әгәр район Башлыгы - район Советы рәисе яки аның урынбасары Балык Бистәсе муниципаль районы Советы сессиясендә юк икән, район Советы утырышта вакытлыча рәислек итүче депутатны үз составыннан сайлый.
2. Район Советы утырышында рәислек итүче:

1) утырышларны ача һәм яба;
2) депутатларга утырышка чакырылганнар составы турында хәбәр итә;
3) район Советы утырышларын алып бара, әлеге регламентның үтәлешен һәм утырышның расланган эш тәртибен тәэмин итә;
4) утырышта кворумның булуын контрольдә тота;
5) докладлар һәм чыгышлар өчен сүз бирә;
6) район Советы карарлары проектларын, утырышта карала торган мәсьәләләр буенча депутатларның тәкъдимнәрен тавыш бирүгә кую эзлеклелеген һәм тавыш бирү нәтиҗәләрен игълан итә;
7) депутатларга секретариаттан кергән гаризаларны, белешмәләрне, тәкъдимнәрне һәм кисәтүләрне игълан итә;
8) утырыш залында тәртип тәэмин итә;
9) карала торган мәсьәләләр буенча хезмәттәшлеккә, якларның позицияләрен якынайтуга ярдәм итә;
10) фикер алышулар барышында фикер алышына торган мәсьәлә буенча төрле фикерләрне ачыклауны тәэмин итә, кирәк булганда тиешле аңлатмалар бирә, фикер каршылыкларын бетерү һәм утырыш барышында барлыкка килә торган башка мәсьәләләрне хәл итү максатларында консультацияләр үткәрүне оештыра;
11) кирәк булганда депутатлар, даими комиссияләр белән консультацияләр үткәрә, каршылыкларны җиңәр өчен вакытлы комиссияләр эшен оештыра;

12) район Советы Секретариаты һәм Аппараты эшен оештыра.

3. Рәислек итүче башка депутатлар өчен әлеге Регламент белән билгеләнгән вакытның асылы буенча чыгыш ясарга, әгәр алар әлеге регламент таләпләренә каршы килмәсәләр, депутатларның чыгышларын өзәргә һәм шәрехләргә хокуклы түгел.

**29 маддә**

1. Район Советы утырышын үткәрү вакытына ачык тавыш бирү белән район Советы депутатларының билгеләнгән саныннан күпчелек тавыш белән район Советы депутатлары арасыннан сайлана:

1) район Советы утырышы секретариаты җитәкчесе һәм әгъзалары;

2) район Советының хисап төркеме җитәкчесе һәм әгъзалары;

2. Әлеге органнарның персональ составы район башлыгы тарафыннан район Советының даими комиссияләре рәисләренең фикерләрен һәм тәкъдимнәрен исәпкә алып кертелә.

3. Район Советы утырышы секретариаты:

1) утырыш беркетмәсен алып баруны оештыра;

2) чыгыш ясаучыларны секретариатка заявкалар керү вакытын күрсәтеп яздыра, утырышта рәислек итүчегә чыгыш ясау өчен язылучылар турында белешмәләр бирә;

3) депутатларның гарызнамәләрен, сорауларын, белешмәләрен, хәбәрләрен, гаризаларын, тәкъдимнәрен һәм башка материалларын теркәп бара, аларны рәислек итүчегә утырышта, редакция комиссиясенә, район Советының башка органнарына җибәрә;

3) утырышта депутатларга кирәкле материалларны күбәйтүне һәм таратуны оештыра;

4) утырышка килүче депутатларны теркәү нәтиҗәләрен анализлый һәм аның утырышларында депутатлар булмау сәбәпләре турында район советына хәбәр итә;

5) тавыш бирү нәтиҗәләрен яздыра;

6) утырыш барышында барлыкка килгән мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирә һәм депутатларга хәбәр итә;

7) район Советы утырышы беркетмәсен рәсмиләштерә һәм аны район Башлыгы - район Советы Рәисе имзасына тәкъдим итә;

8) район Советы депутатлары эшчәнлеген тәэмин итү буенча башка функцияләр башкара.

4. Депутатларның район Советы буенча мөрәҗәгатьләрен һәм фикерләрен тулырак исәпкә алу, рәислек итүче яки башка депутатлар тәкъдиме буенча карар проектының соңгы текстын эшләү өчен утырышта редакция комиссиясе сайлана.

**30 маддә**

1. Район Советының чираттагы утырышы көн тәртибе һәм эш тәртибе, район Советының эш планнарын һәм карарларын, шулай ук кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, район Башлыгы - район Советы рәисе тарафыннан әзерләнә һәм район Советы каравына тапшырыла. Чираттагы утырышның көн тәртибенә мәсьәләләрне кертү буенча инициатива хокукына район Башлыгы - район Советы рәисе, район Советы депутатлары, даими комиссияләр, район Башкарма комитеты җитәкчесе, район Уставы нигезендә хокук чыгару инициативасының башка субъектлары ия.

Район Советының чираттан тыш утырышларының көн тәртибе аларны үткәрү инициаторы белән беркетелә. Чираттан тыш утырышны үткәрү инициаторлары язма рәвештә үзләре тәкъдим иткән мәсьәләне ашыгыч рәвештә карау зарурлыгын нигезләүне, шулай ук әлеге Регламент нигезендә район Советы утырышында карау өчен документларны тапшырырга тиешләр.

1.Район Советы утырышының көн тәртибе һәм эш тәртибе рәислек итүче тәкъдиме буенча утырышта район Советы тарафыннан тикшерелә һәм раслана.

2.Район Советы утырышының көн тәртибенә һәм эш тәртибенә тәкъдимнәр һәм искәртүләр район Советы депутатлары тарафыннан утырыш Секретариатына язмача тапшырыла яки алар чыгышларында бәян ителә. Язмача кергән тәкъдимнәр утырышта рәислек итүчеләргә аларның керү тәртибендә игълан ителә.

3.Көн тәртибендәге мәсьәләләрне карау тәртибе, чираттагы мәсьәләне карауга күчү яки алдагы, әмма хәл ителмәгән мәсьәләләрнең берсенә кире кайтару, утырышта катнашучы депутатлар саныннан күпчелек тавыш белән яисә депутатларның каршылыклары булмаганда рәислек итүче тавыш белән гамәлгә ашырыла.

4. Район Советы район Советы утырышында расланган көн тәртибендәге барлык мәсьәләләрне карарга яки каралмаган мәсьәләләрне киләсе утырышка күчерү турында карар кабул итәргә тиеш. Күчерелгән мәсьәләләр икенче утырышның көн тәртибендә, әгәр башка карар район Советы тарафыннан кабул ителмәсә, аларны карау вакыты буенча өстенлеккә ия.

**31 маддә**

1. Район Советы утырышына материаллар депутатларга, район Башкарма комитеты җитәкчесенә, хокук чыгару инициативасының башка субъектларына утырышка кадәр 3 көннән дә соңга калмыйча җибәрелә.

2. Район бюджеты проектлары, районның үсеш планнары һәм программалары, аларның үтәлеше турында хисаплар, район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр буенча материаллар утырышка кадәр 5 көннән дә соңга калмыйча җибәрелә.

**32 маддә**

a. Район Советы утырышлары 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр уздырыла. Район Советы утырышының башка вакытын район Башлыгы - район Советы утырышын чакыру турында карар кабул иткәндә район Советы рәисе билгели ала. Утырышны үткәрү вакытын озайту район Советы тарафыннан утырышта рәислек итүче тәкъдиме буенча кабул ителә.

b. Көн тәртибе (вакыт һәм тәнәфесләр саны) утырыш башында рәислек итүче тәкъдиме буенча район Советы тарафыннан раслана.

c. Утырышта докладлар өчен вакыт, кагыйдә буларак, 15 минут, өстәмә докладлар өчен - 10 минут, докладлар һәм карарлар проектлары буенча фикер алышуларда - 5 минутка кадәр, фикер алышуларда кабат чыгыш ясау өчен - 3 минутка кадәр, утырышларны алып бару тәртибе буенча чыгышлар, тавыш бирү мотивлары, сораулар, тәкъдимнәр, хәбәрләр һәм белешмәләр кертү өчен - 1 минутка кадәр бирелә.

d. Билгеләнгән вакыттан соң рәислек итүче бу хакта хәбәр итә, ә аннары аның чыгышын өзәргә хокуклы.

2. Депутатларның күпчелеге ризалыгы белән яисә депутатларның каршы килүләре булмаганда тавыш бирмичә, рәислек итүче доклад, өстәмә доклад яки чыгыш ясау өчен вакытны озайтырга яки кыскартырга хокуклы.

3. Һәр утырыш ахырында, гаризалар килсә, көн тәртибенең «төрлеләр» кысаларында сылтамалар, белдерүләр, мөрәҗәгатьләр, гаризалар өчен 30 минут вакыт бирелә. Бу хәбәрләр буенча бәхәс ачылмый.

**33 маддә**

е. Район Советы утырышының көн тәртибе буенча доклад һәм өстәмә докладтан соң депутатларга докладчыга, өстәмә докладчыга сораулар бирү мөмкинлеге бирелә. Сораулар язмача яки телдән бирелә. Депутат өчтән артык сорау бирә алмый.

f. Кирәк булганда район Советы депутатлар саныннан күпчелек тавыш белән доклад яки район Советы карары проекты буенча мәсьәләләрне туктату һәм фикер алышуларга күчү турында карар кабул итә.

g. Көн тәртибендәге барлык мәсьәләләр буенча («төрле» мәсьәләдән тыш) каршылык мәҗбүри рәвештә ачыла.

h. Депутат фикер алышуларда ике тапкырдан да артык чыгыш ясый алмый. Өстәмә чыгыш ясау хокукы бары тик район Советы карары белән генә бирелә ала. Чыгыш ясау хокукын башка затка тапшыру рөхсәт ителми.

i. Утырышта депутатлар саныннан күпчелек тавыш белән ачык тавыш бирү белән кабул ителә торган район Советы карары буенча фикер алышулар туктатыла. Фикер алышуларны туктату турындагы мәсьәләне хәл иткәндә рәислек итүче депутатларга чыгыш ясау өчен язылучылар саны һәм аларның кайсылары чыгыш ясарга теләвен ачыклау өчен хәбәр итә. Әгәр депутат фикер алышулар туктатылуга бәйле рәвештә чыгыш ясау мөмкинлеген алмаган икән, ул үз чыгышының текстын секретариатка аның район Советы утырышы беркетмәсенә кушымтасы өчен тәкъдим итә ала. Фикер алышуларны туктатканнан соң, докладчы һәм өстәмә доклад ясаучы 5 минут эчендә йомгаклау чыгышына хокуклы.

**34 маддә**

1. Район Советы депутаты, утырышта катнашучы башка зат рәислек итүче сүз биргәннән соң чыгыш ясый. Чыгыш өчен сүз гаризалар кабул итү тәртибендә бирелә. Утырышны алып бару тәртибе буенча рәислеккә искәртүләрне белдерү өчен, шулай ук тавыш бирүгә куелган формулировкаларны ачыклау чираттан тыш тәкъдим ителә. Рәислек итүче тарафыннан шулай ук, белешмәләр, аңлатмалар бирү һәм башка процедура мәсьәләләре буенча чыгыш ясау өчен мөмкинлек бирү искәрмә буларак эшләнергә мөмкин.

2. Район Советы тикшерелә торган мәсьәлә буенча чыгышларның чиратын үзгәртергә хокуклы.

**3.** Алдан язылмыйча, чираттан тыш чыгыш ясау хокукына район Башлыгы - район Советы рәисе, район Башкарма комитеты җитәкчесе, утырышта рәислек итүче затлар ия.

**35 маддә**

1. Район Советы утырышында район Советы депутаты сүз алган көн тәртибенең асылы буенча чыгыш ясарга тиеш. Беркем дә район Советы

депутатларының чыгышларына аңлатма бирергә, чыгыш ясаучыларга характеристика бирергә хокуклы түгел.

2. Район Советы утырышында чыгыш ясаучы тупас һәм әдәпсез сүзләр әйтергә, законсыз һәм көч куллануга чакырырга тиеш түгел. Бу таләпләр бозылганда, рәислек итүче мондый сүзләр, чакырулар һәм гамәлләр булмасын өчен рәсми кисәтү ясый.

3. Кабат бозылганнан соң рәислек итүче депутатның чыгышын өзә. Әлеге депутат утырыш дәвамында район Советы карары белән дә сүздән мәхрүм ителергә мөмкин, ул депутатлар саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

4. Әгәр чыгыш ясаучы карала торган темадан читкә тайпылса, рәислек итүче аны тикшерелә торган мәсьәлә темасыннан читкә тайпылмаска чакырырга хокуклы.

**36 маддә**

Утырышта катнашкан һәм район Советы депутаты булып тормаган зат тарафыннан тупас хокук бозулар булса, рәис күрсәтмәсе буенча ул утырыш залыннан чыгарылырга мөмкин.

**37 маддә**

1. Район Советының һәр утырышында беркетмә алып барыла. Техник мөмкинлек булган очракта, фонограмма һәм стенограмма алып барылырга мөмкин.
2. Утырыш беркетмәсендә күрсәтелә:

a. утырышны уздыру датасы, урыны һәм район Советы утырышының тәртип номеры;

b. депутатларның билгеләнгән саны, утырышта катнашучылар саны, аларның фамилиясен, исемен, атасының исемен күрсәтеп;

c. рәислек итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы;

d. район Советы утырышының көн тәртибенә куелган мәсьәләләр, докладчылар һәм район Советы каравына чыгарылган һәр мәсьәлә буенча чыгыш ясаучыларның фамилияләре, инициаллар;

i. тавыш бирү өчен барлык тәкъдимнәрнең формулировкалары һәм барлык тавыш бирү нәтиҗәләре, яклап яки каршы тавыш бирүчеләр яки тыелып калган депутатлар санын күрсәтеп, ә исемле тавыш биргәндә - шулай ук депутатларның фамилияләре һәм инициаллары.

e. Беркетмәгә карарлар проектлары һәм аңа бәйле материаллар, чыгышларның текстлары яки тасвирламалары һәм утырыш барышында депутатлар һәм чыгыш ясаучылар тарафыннан секретариатка тапшырылган башка материаллар, район Советы кабул иткән актларның тулы текстлары теркәлә.

f. Район Советы утырышы беркетмәсе район Советы утырышы тәмамланганнан соң биш көн эчендә рәсмиләштерелә, секретариат әгъзалары тарафыннан визалана һәм район Башлыгы – район Советы рәисе тарафыннан имзалана. Район Советы утырышының стенограммасын секретариат әгъзалары имзалый.

Беркетмә ике нөсхәдә рәсмиләштерелә. Беренчесе билгеләнгән тәртиптә архивка тапшырыла. Беркетмәнең икенче нөсхәсе район Советы аппаратында һәм алар үтенече буенча район Советы депутатларына һәм район халкына таныштыру өчен бирелә.

## 6 Бүлек. Тавыш бирү һәм карар кабул итү тәртибе

**38 маддә**

1. Район Советы карарлары, кагыйдә буларак, ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә.
2. Законнарда, район Уставында һәм әлеге Регламентта каралган очракларда, шулай ук район Советы карары буенча яшерен тавыш бирү уздырыла.
3. Район Советы карары буенча исемле тавыш бирү үткәрелергә мөмкин. Исемләп тавыш бирү кадрлар мәсьәләсе буенча үткәрелә алмый.

**39 маддә**

1. Ачык тавыш бирүне уздырганда тавышларны санауны хисап төркеме алып бара.

2. Тавыш бирү алдыннан рәислек итүче тавыш бирүгә куела торган тәкъдимнәр саны турында хәбәр итә, аларның формулировкаларын һәм аларның тавыш бирүгә куелган эзлеклелеген ачыклый, нинди тавышлар кабул ителүен искә төшерә.

3. Бер яки ике тәкъдим буенча тавыш биргәндә, һәр депутат бер тапкыр үз тавышын бирергә хокуклы: «яклап» яки аңа «каршы", шулай ук тавыш бирүдән тыелырга. Әгәр аның өчен әлеге регламент буенча кирәкле депутатлар саны тавыш бирсә, тәкъдим кабул ителгән дип санала.

4. Әгәр тавыш бирүгә бер мәсьәлә буенча ике тәкъдимнән артык чыгарылса, һәр депутат үз тавышын Һәр тәкъдимгә «яклап» яки «каршы» бирергә, шулай ук теләсә кайсы тәкъдим буенча тавыш бирүдән (рейтинглы тавыш бирү) тыелырга хокуклы. Иң күп тавыш җыйган ике тәкъдим бу маддәнең өченче өлешендә каралган тәртиптә кабат тавыш бирүгә чыгарыла. Әгәр бу очракта тәкъдимнәрнең берсе дә әлеге регламент буенча карар кабул итү өчен кирәкле тавышлар санын алмаган булса, рәислек итүче тәкъдиме буенча яңа карар проектын эшләү өчен депутатлардан килештерү комиссиясе төзелә.

5. Тавыш бирүдән соң рәислек итүче аның нәтиҗәләрен игълан итә. Тавыш бирү нәтиҗәләре район Советы утырышы беркетмәсенә кертелә.

**40 маддә**

1. Яшерен тавыш бирүне уздыру һәм аның нәтиҗәләрен билгеләү өчен район Советы депутатлар арасыннан хисап комиссиясен сайлый. Хисап комиссиясенә сайланулы органнар составына яисә сайланулы вазыйфаларга тәкъдим ителгән депутатлар керә алмый.
2. Хисап комиссиясе үз составыннан комиссия рәисен һәм секретарен сайлый, бу турыда беркетмә төзелә.
3. Комиссия карарлары аның әгъзаларының күпчелек тавышлары белән кабул ителә һәм комиссия рәисе һәм секретаре имзалаган протоколлар белән рәсмиләштерелә.

4. Тавыш бирү өчен бюллетеньнәр хисап комиссиясе контроле астында билгеләнгән формада һәм билгеле санда әзерләнә. Бюллетеньнәрдә тавыш бирү өчен кирәкле мәгълүмат булырга тиеш. Карар проектлары буенча тавыш бирү бюллетеньнәрендә яки сайлау вазыйфасына бердәнбер кандидатура булганда «яклап» һәм «каршы " сүзләре торырга тиеш.

5. Тавыш бирү вакыты һәм урыны, аны үткәрү тәртибе әлеге регламент нигезендә хисап комиссиясе тарафыннан билгеләнә һәм комиссия рәисе тарафыннан игълан ителә.

6. Тавыш бирү өчен комиссия утырышта катнашкан һәр депутатка тавыш бирү өчен бер бюллетень бирә.

7. Бюллетеньне тутыру бюллетеньдә депутат тавыш бирә торган кандидат фамилиясен сызып төшерү юлы белән башкарыла, ә бюллетеньдә (карар варианты) бер кандидатура белән карар проекты буенча - тәкъдим ителгән карарларның вариантлары яки кандидат фамилиясе янында «яклап» яки «каршы» сүзләре. Барлык кандидатларның фамилияләрен яисә фамилияләрен сызу, шулай ук бюллетеньне тутырмау тавыш бирүдән тыелган дип санала.

6. Тавыш бирү бюллетене тавыш бирү кабинасында тутырыла һәм мөһерләнгән тавыш бирү савытына (урнага) төшерелә.

7. Тавыш бирү тәмамлангач, хисап комиссиясе урнаны ача, дөрес һәм яраксыз бюллетеньнәр санын билгели һәм тәкъдим өчен яки аңа каршы тавышларны саный. Тавышларны санаганда район Советы депутатлары да катнаша ала.

8. Ачыкланмаган формадагы бюллетеньнәр, ә вазыйфаи затны сайлаганда - бер вазыйфага ике яки аннан күбрәк кандидатның фамилияләре калган бюллетеньнәр гамәлдә түгел дип санала.

9. Яшерен тавыш бирү нәтиҗәләре турында хисап комиссиясе беркетмә төзи, ул хисап комиссиясенең барлык әгъзалары тарафыннан имзалана һәм район Советы утырышында укыла. Хисап комиссиясе доклады буенча район Советы яшерен тавыш бирү нәтиҗәләрен раслау турында карар кабул итә.

**41 маддә**

1. Исемле тавыш бирү район Советы депутатларының билгеләнгән саныннан кимендә биштән бере таләбе буенча үткәрелә.
2. Исемле тавыш бирүне уздыру һәм аның нәтиҗәләрен билгеләү өчен район Советы депутатлар арасыннан хисап комиссиясен сайлый.
3. Район Советы утырышында яшерен һәм исемле тавыш бирү уздырылган очракта, район Советы аларны оештыруны хисап комиссиясенең бер составына йөкләргә мөмкин.

Исемле тавыш бирү нәтиҗәләре секретариатка беркетмәгә кертү өчен бирелә һәм район Советы утырышында игълан ителә, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында басыла.

**42 маддә**

1. Шул ук мәсьәлә буенча кабат тавыш бирү район Советы карары буенча кабул ителә, бу мәсьәлә буенча карар кабул итү өчен кирәк булган шул ук күпчелек тавыш белән. Моның өчен нигез булып тавышларны санаганда хаталар, тавыш бирүгә сорау куйганда аңлашылмаучанлык, әлеге регламентны башкача бозу булырга мөмкин.

**43 маддә**

1. Процедура мәсьәләләре буенча карарлар, әгәр әлеге Регламентта башкасы билгеләнмәгән булса, утырышта катнашучылар саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә һәм утырыш беркетмәсендә чагылдырыла.
2. Процедураларга түбәндәге сораулар керә:

1) утырышның көн тәртибе проектына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында;

2) утырышның көн тәртибен раслау турында;

3) утырышның көн тәртибен яңа сорау белән тулыландыру турында;

4) район Советы секретариатына һәм башка органнарга җитәкче һәм әгъзалар сайлау турында;

5) утырышны берничә этапта уздыру турында;

6) утырыштагы тәнәфес, утырышны күчерү яки ябу турында;

7) чыгыш ясау өчен өстәмә вакыт бирү турында;

8) утырышның көн тәртибе мәсьәләсе буенча фикер алышуларны күчерү яки туктату турында;

